Әлеге Закон Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруның аерым мәсьәләләрен җайга сала.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Күпфатирлы йорттагы урын милекчесе (алга таба – урын милекчесе) үзенә карый торган урынны тоту чыгымнарын башкарырга, шулай ук торак урынны тоту һәм аңа ремонт өчен түләү һәм күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр (алга таба – капиталь ремонт өчен кертем) кертү юлы белән күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тоту чыгымнарында бу мөлкәткә гомуми милек хокукындагы үз өлешенә карап катнашырга тиеш.

2. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонтка чыгымнар күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт фонды (алга таба – капиталь ремонт фонды) акчалары исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) җирле бюджет акчалары исәбеннән һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклардан финанслана.

3. Урыннар милекчеләре, Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очраклардан тыш, әлеге Законның 9 статьясы нигезендә билгеләнгән күләмдә яисә,

урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән булса, зуррак күләмдә капиталь ремонт өчен айлык кертемнәр түләргә тиеш.

4. Урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы әлеге күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча расланган региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап ике календарь ай үткәннән соң барлыкка килә.

5. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәт объектларын файдалануга бирүдән керемнәр, торак милекчеләре ширкәте акчалары, шул исәптән торак милекчеләре ширкәтенең хуҗалык эшчәнлегеннән алынган керемнәр, Россия Федерациясе Торак кодексы, торак милекчеләре ширкәте уставы нигезендә кабул ителгән урыннар милекчеләре карары, торак милекчеләре ширкәте әгъзалары карары буенча урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәрне түләү бурычын үтәү исәбенә капиталь ремонт фонды булдыруга юнәлдерелә ала.

6. Урыннар милекчеләре капиталь ремонт фонды булдыруның түбәндәге алымнарыннан берсен сайлап алырга хокуклы:

1) капиталь ремонт өчен кертемнәрне махсус счеттагы акчалата капиталь ремонт фонды булдыру максатларында махсус счетка күчерү;

2) капиталь ремонт өчен кертемнәрне урыннар милекчеләренең региональ операторга карата йөкләмә хокуклары рәвешендә капиталь ремонт фонды булдыру максатларында региональ оператор счетына күчерү.

7. Капиталь ремонт фонды булдыру алымы Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән тәртиптә урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары нигезендә теләсә кайсы вакытта үзгәртелергә мөмкин.

8. Махсус счет банкта Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә һәм Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып ачыла.

9. Үз исеменә махсус счет ачыла торган зат (алга таба – махсус счет хуҗасы) түбәндәгеләр булырга мөмкин:

1) күпфатирлы йортка идарә итүне гамәлгә ашыручы һәм бер күпфатирлы йортта яисә барлыгы 30дан артык фатиры булмаган берничә күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тарафыннан оештырылган торак милекчеләре ширкәте, әгәр бу йортлар дәүләт күчемсез мөлкәт кадастрындагы документлар нигезендә уртак чиге булган һәм үз чикләрендә шушы йортлардагы урыннар милекчеләренең бергәләшеп файдалану өчен билгеләнгән инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре, инфраструктураның башка элементлары булган җир кишәрлекләрендә урнашкан булса;

2) күпфатирлы йортка идарә итүне гамәлгә ашыручы торак кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы;

3) урыннар милекчеләре гомуми җыелышта региональ операторны махсус счет хуҗасы буларак сайлау турында карар кабул иткән очракта күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган махсуслаштырылган оешма (алга таба – региональ оператор).

10. Региональ оператор Россия Федерациясе Торак кодексы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелә.

3 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү;

2) Татарстан Республикасы тарафыннан бирелә торган дәүләт ярдәме акчалары исәбеннән финансланырга мөмкин күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеген билгеләү;

3) региональ оператор төзү, региональ операторның мөлкәтен формалаштыру һәм эшчәнлеге тәртибен билгеләү, региональ операторның гамәлгә кую документларын раслау;

4) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелергә тиешле өстәмә белешмәләрне билгеләү;

5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын раслау тәртибен билгеләү;

6) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын раслау;

7) капиталь ремонт өчен кертемнәр исәбеннән формалаштырылган акчаларның саклануын тәэмин итүне һәм шушы акчаларның максатчыл тотылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

8) региональ оператор эшчәнлегенең законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

9) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яисә) күрсәтелгән хезмәтләрне урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында кабул итү тәртибен билгеләү;

10) урыннар милекчеләренә махсус счет хуҗасы һәм (яисә) региональ оператор тарафыннан капиталь ремонт фонды акчаларын түләү һәм җибәрү тәртибен, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда капиталь ремонт фонды акчаларыннан күпфатирлы йортны сүтү яисә реконструкцияләү максатларында файдалану тәртибен билгеләү;

11) капиталь ремонт фонды булдыру алымын билгеләү турында урыннар милекчеләре тарафыннан карар кабул итүнең һәм аны гамәлгә ашыруның срогын билгеләү;

12) региональ операторның еллык бухгалтерлык (финанс) хисабына аудит үткәрү турында карар кабул итүнең, аудитор оешмасы (аудитор) белән шартнамәне раслау тәртибен билгеләү, конкурс нигезендә аудитор оешмасын (аудиторны) сайлап алуны башкару;

13) региональ операторның еллык хисабын һәм аудитор бәяләмәсен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштыру тәртибен һәм срокларын билгеләү;

14) Россия Федерациясе Торак кодексында һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Архитектура, шәһәр корылышы, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендәге, торак һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының (алга таба – вәкаләтле орган) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) күпфатирлы йортларның техник торышына мониторинг үткәрү тәртибен билгеләү;

2) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү максатларында региональ оператор белән үзара эш итү;

3) үз исеменә махсус счет ачылган зат һәм региональ оператор тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 177 статьясындагы 7 өлеше һәм 183 статьясы нигезендә тапшырылырга тиешле белешмәләрне тапшыру тәртибен билгеләү;

4) региональ оператор, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда, җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен подряд оешмаларын җәлеп итү тәртибен билгеләү;

5) Россия Федерациясе Торак кодексында, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле муниципаль берәмлек территориясендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын раслау;

2) Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда региональ оператор счетында капиталь ремонт фонды булдыру турында карарлар кабул итү;

3) Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа һәм региональ оператор тәкъдимнәре нигезендә капиталь ремонт ясау турында карарлар кабул итү;

4) федераль законнарда һәм әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Региональ оператор эшчәнлеге мәсьәләләре**

1. Региональ оператор фонд оештыру-хокукый рәвешендәге төзелгән юридик зат булып тора. Региональ оператор Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә төзелә.

2. Региональ оператор эшчәнлеге, Россия Федерациясе Торак кодексы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Региональ операторның функцияләре түбәндәгеләр:

1) капиталь ремонт фондлары региональ оператор счетында, счетларында булдырыла торган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан түләнә торган капиталь ремонт өчен кертемнәрне туплау;

2) урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында урыннар милекчеләре махсус счет хуҗасы буларак региональ операторны сайлаган очракта үз исеменә махсус счетлар ачу һәм әлеге счетлар буенча операцияләр башкару. Региональ оператор күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан үз исеменә мондый счет ачудан баш тартырга хокуксыз;

3) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләрнең техник заказ бирүчесе функцияләрен гамәлгә ашыру;

4) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт чыгымнарын әлеге капиталь ремонт фондлары акчалары чикләрендә, кирәк булганда, башка чыганаклардан, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджеттан алынган акчаларны җәлеп итеп финанслау;

5) урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эш итү;

6) Россия Федерациясе Торак кодексында, әлеге Законда һәм региональ операторның гамәлгә кую документларында каралган башка функцияләр.

4. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт чыгымнарын финанслау региональ оператор тарафыннан капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдыру турында карар кабул иткән урыннар милекчеләре белән, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 7 өлешендә каралган очракта капиталь ремонт фонды булдыру алымы хакында карар кабул итмәгән урыннар милекчеләре белән төзелгән капиталь ремонт фонды булдыру һәм капиталь ремонт ясауны оештыру турында шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тавышларының гомуми саныннан 50 проценттан артык тавышка ия булучы урыннар милекчеләре төзелә торган шартнамәдә бер як буларак эш итә.

5. Региональ оператор тарафыннан капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган бер күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләреннән алынган акчалар кире кайтару нигезендә урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын шушы ук региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган башка күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны финанслау өчен файдаланылырга мөмкин. Акчалардан болай файдалану күрсәтелгән күпфатирлы йортлар бер муниципаль берәмлек территориясендә урнашканда гына рөхсәт ителә.

6. Татарстан Республикасы территориясендә бер региональ оператор төзелгән һәм эш иткән очракта, урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләренең техник заказчысы функцияләре региональ оператор белән төзелгән тиешле шартнамә нигезендә җирле үзидарә органнары һәм (яисә) муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

7. Региональ оператор эшчәнлеге турындагы мәгълүмат региональ операторның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Региональ оператор Россия Федерациясе Торак кодексының 183 статьясындагы 2 өлешендә каралган белешмәләрне сорату буенча урыннар милекчеләренә, шулай ук бу күпфатирлы йортка идарә итү өчен җаваплы затка (торак милекчеләре ширкәтенә, торак кооперативына яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативына, идарә итүче оешмага) һәм, әлеге күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре аңа турыдан-туры идарә иткәндә, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затка тапшыра.

6 статья. **Региональ оператор эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгына таләпләр**

1. Региональ операторның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны финанслауга ел саен тотылырга хокуклы акчалар күләме (гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт киләсе чорда булырга тиеш күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан булдырылган капиталь

ремонт фондлары акчалары исәбеннән бирелә торган акчалар күләме) региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән өлеш буларак билгеләнә. Күрсәтелгән өлешнең күләме региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән 92 процентны тәшкил итә. Региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән калган сигез проценты региональ операторга агымдагы елда кергән акчалар күләмендә исәпкә алынырга һәм киләсе елда капиталь ремонтны финанслау максатларында файдаланылырга тиеш.

2. Региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән керемнәр күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетлардан һәм башка чыганаклардан алынган акчалар исәпкә алынмый.

3. Региональ оператор эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын тәэмин итүгә өстәмә таләпләр түбәндәгеләр:

1) региональ оператор тарафыннан вакытлыча ирекле акчаларны урнаштыру шартлары капиталь ремонт ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яисә) башкарылган эшләр өчен исәп-хисап ясаганда акчалар кытлыгы барлыкка килүгә, шул исәптән региональ оператор һәм капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яисә) эшләр башкаручы оешма арасында төзелгән шартнамәдә каралган җаваплылыкка региональ операторны тарту очрагына китермәскә тиеш;

2) региональ оператор тарафыннан вакытлыча ирекле акчаларны урнаштыру шартлары региональ операторның күрсәтелгән эшчәнлегеннән керемнәрнең даими артуын күздә тотарга тиеш;

3) кредитлар һәм (яисә) заемнар региональ оператор тарафыннан Региональ операторның попечительлек советы ризалыгы белән генә җәлеп ителергә мөмкин;

4) капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча региональ операторга бурыч проценты региональ операторга урыннар милекчеләреннән керергә тиешле акчаларның гомуми күләменнән 30 проценттан артыкны тәшкил итмәскә тиеш;

5) региональ операторның дебитор бурычы проценты региональ операторның агымдагы эшчәнлеген финанслауга каралган сметадагы гомуми күләмнең 30 процентыннан артмаска тиеш. Монда региональ оператор счетындагы, счетларындагы капиталь ремонт фонды акчалары исәпкә алынмый. Күрсәтелгән өлешне арттыру региональ операторның эшчәнлегенә тикшерү үткәрү һәм дебитор бурычны юк итүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар күрү өчен нигез булып тора.

7 статья. **Региональ оператор эшчәнлеген тикшереп тору**

1. Региональ оператор эшчәнлегенең законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшереп тору Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасының дәүләт финанс контроле органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль финанс контроле органнары, Россия

Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап һәм финанс органнары региональ операторның тиешле бюджетлар акчаларыннан файдалануга финанс контролен Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыралар.

3. Хокук бозулар ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары ачыкланган закон таләпләрен бозуларны бетерү турында региональ операторга тәкъдимнәр һәм (яисә) күрсәтмәләр җибәрә.

8 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру тәртибе**

1. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча капиталь ремонтка кертемнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлегенә түбәндәгеләр керә:

1) йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су җибәрү инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру;

2) файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазын ремонтлау яисә алмаштыру, лифт шахталарын ремонтлау;

3) түбә ремонтлау, шул исәптән җилләнми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу җайланмалары ясау;

4) күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә карый торган идән асты бүлмәләрен ремонтлау;

5) фасадны җылыту һәм ремонтлау;

6) коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпләүнең коллектив (гомумйорт) приборларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллануга идарә итү һәм аны җайга салу узелларын урнаштыру яисә алмаштыру;

7) күпфатирлы йорт нигезен ремонтлау;

8) күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау;

9) күпфатирлы йортка энергетика тикшерүе үткәрү;

10) проект документациясенә дәүләт экспертизасы эшләү һәм үткәрү (проект документациясен әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә кирәк булган очракта);

11) төзелеш контролен башкару;

12) күпфатирлы йортның янгынга каршы саклану системасын ремонтлау.

2. Капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне күпфатирлы йортта торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләүче оешма тарафыннан бирелгән түләү документлары нигезендә, әгәр күпфатирлы йортка идарә итү шартнамәсе йә торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яисә башка махсуслаштырылган

кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән бүтән срок билгеләнмәгән булса, узган айдан соң килүче айның беренче числосыннан да соңга калмыйча түлиләр. Урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүне кертү өчен билгеләнгән срокларда түлиләр. Капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү документларында күрсәтелгән региональ операторның счетына күчерелә.

3. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итүдә урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар, шулай ук җирле үзидарә органнары катнаша.

4. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа белән билгеләнгән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срогы җиткәнче шушы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада каралган аерым эшләр башкарылса, бу эшләргә түләү бюджет акчаларыннан һәм региональ оператор акчаларыннан файдаланмыйча гына гамәлгә ашырылган булса, һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта әлеге эшләрне яңадан эшләү таләп ителмәсә, шушы эшләрнең хакына тигез булган, әмма әлеге эшләрнең Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик хакыннан артык булмаган күләмдәге акчалар капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыручы урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәрне түләү буенча йөкләмәләрен киләчәк чорда үтәү исәбенә кертеләләр.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очракта акчаларны исәпкә кертү капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыручы урыннар милекчеләренең йә урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның үзләренең капиталь ремонт өчен кертемнәрне түләү буенча йөкләмәләрен киләчәк чорда үтәү исәбенә кертеп гамәлгә ашыру турында гариза белән региональ операторга мөрәҗәгать иткәндә башкарыла. Гаризага күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яисә) башкарылган эшләр өчен подряд оешмасына түләүне раслый торган документлар һәм әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә рәсмиләштерелгән, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы һәм вәкаләтле орган белән килештерелгән күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актлары кушып бирелә.

6. Региональ оператор тапшырылган документларның керү датасыннан 30 көн дәвамында аларны тикшереп чыга һәм исәпкә кертү турында карар яисә исәпкә кертүдән баш тарту хакында дәлилле карар кабул итә, шул хакта тиешле карар кабул итү датасыннан 10 көн дәвамында урыннар милекчеләренә хәбәр итә.

9 статья. **Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү тәртибе**

1. Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы раслаган методик рекомендацияләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме, күпфатирлы йорттагы урын милекчесенә карый торган урынның гомуми мәйданыннан чыгып, күпфатирлы йортның төрен һәм ничә катлы булуын, күпфатирлы йорттагы төзелеш конструкцияләренең аерым элементларына һәм инженерлык системаларына капиталь ремонт ясау хакын, чираттагы капиталь ремонт ясаганчы алардан нәтиҗәле файдалануның норматив срокларын (ремонтара норматив сроклар), шулай ук күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Россия Федерациясе Торак кодексында, әлеге Законда билгеләнгән эшләр исемлеген исәпкә алып билгеләнә.

3. Вәкаләтле орган капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләүне һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрүне тәэмин итә.

10 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа әзерләү һәм раслау тәртибе, шундый программаларга таләпләр**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны (алга таба – капиталь ремонт буенча региональ программа) әзерләү һәм раслау Россия Федерациясе Торак кодексы һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Капиталь ремонт буенча региональ программа Татарстан Республикасы торриториясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кирәкле срокка төзелә һәм даими нигездә гамәлдә була.

3. Капиталь ремонт буенча региональ программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Капиталь ремонт буенча региональ программага түбәндәгеләр керә:

1) капиталь ремонт буенча региональ программаның төп максатлары һәм бурычлары;

2) капиталь ремонт буенча региональ программаны үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре;

3) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган муниципаль адреслы программаларга кертелгән барлык күпфатирлы йортлар, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән

тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлардан тыш, исемлеге;

4) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге;

5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның план елы, шул исәптән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча һәр эш төрен башкару сроклары;

6) капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән региональ оператор тарафыннан түләнергә мөмкин булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе күләме;

7) Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелергә тиешле башка белешмәләр.

5. Күпфатирлы йортларга идарә итүче затлар әлеге Закон үз көченә кергән көннән бер ай дәвамында капиталь ремонт буенча региональ программаны төзү өчен җирле үзидарә органнарына үзләре идарә итә торган күпфатирлы йортлар турында вәкаләтле орган тарафыннан расланган рәвештә мәгълүмат тапшыралар.

6. Җирле үзидарә органы әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән срок тәмамланганнан соң бер ай дәвамында кергән мәгълүматны гомумиләштерә, шулай ук күпфатирлы йортларга идарә итүче затлар тарафыннан әлеге йортлар буенча тапшырылмаган мәгълүматны җыя. Гомумиләштерелгән мәгълүмат нигезендә җирле үзидарә органнары капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа раслый.

7. Расланган капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа һәм муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар турында гомумиләштерелгән мәгълүмат әлеге Закон үз көченә кергән көннән ике айдан да соңга калмыйча җирле үзидарә органы тарафыннан вәкаләтле органга тапшырыла.

8. Муниципаль адреслы программалар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган белешмәләр нигезендә вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программа проектын төзи һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрә.

9. Капиталь ремонт буенча региональ программа кимендә елга бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш.

10. Капиталь ремонт буенча региональ программага күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонтның билгеләнгән срогын соңрак вакытка күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләр кертү, әлеге күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тиешле карар кабул иткән очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

11. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын

конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнарын расларга тиеш.

11 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийлары**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгы капиталь ремонт буенча региональ программада әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә билгеләнә.

2. Капиталь ремонт буенча региональ программа белән беренче чиратта түбәндәгеләргә капиталь ремонт ясау күздә тотылырга тиеш:

1) капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау яисә актуальләштерү датасына мондый капиталь ремонт ясалмаган булса, беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына капиталь ремонт ясау таләп ителгән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеге билгеләнү тәртибендә капиталь ремонт таләп ителгән күпфатирлы йортларга.

3. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийлары түбәндәгеләр:

1) техник критерийлар:

а) күпфатирлы йортта капиталь ремонт планлаштырыла торган гомуми мөлкәт объектларының техник торышы;

б) файдалануга тапшырылганнан соң яисә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә соңгы комплекслы капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортны эксплуатацияләү дәвамлылыгы;

в) проект документациясен әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәк булган очракта, мондый документациянең булуы;

г) күпфатирлы йортта энергетика тикшерүе нәтиҗәләре буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән энергетика паспортының булуы;

2) оештыру критерийлары:

а) урыннар милекчеләренең капиталь ремонт ясау турындагы карарны хуплау дәрәҗәсе;

б) җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр исәбен булдыру һәм үткәрү эшләрен башкаруны раслый торган документларның булуы;

3) капиталь ремонтны финанслауда урыннар милекчеләренең өлешен белдерә торган финанс критерие.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән чиратлылык билгеләү критерийларын куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

12 статья. **Капиталь ремонт фонды булдыруны тикшереп тору**

1. Махсус счет хуҗасы Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына түбәндәге белешмәләрне тапшырырга тиеш:

1) тиешле күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фонды булдыруның сайлап алынган алымы турында хәбәрнамә, аңа түбәндәгеләр кушып бирелә:

а) Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләрендә каралган карарларны кабул итү турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсе;

б) махсус счет ачу турында банк белешмәсе;

в) күпфатирлы йортка идарә итү алымын сайлап алу турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәләренең күчермәләре;

г) күпфатирлы йорт турында мәгълүмат (күпфатирлы йортның ничә катлы булуы, гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак урыннарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, файдалануга тапшыру елы, соңгы капиталь ремонт ясау елы);

2) капиталь ремонт фондларын махсус счетта булдыручы урыннар милекчеләреннән капиталь ремонт өчен кертемнәрнең керүен раслый торган документлар;

3) махсус счетта калган акчаларның күләме турында мәгълүмат.

2. Региональ оператор Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын региональ оператор счетында, счетларында булдыра торган күпфатирлы йортлар турында, шулай ук мондый күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләреннән капиталь ремонт өчен кертемнәрнең керүе турында түбәндәге белешмәләрне тапшырырга тиеш:

1) күпфатирлы йортка идарә итү алымын сайлап алу турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәләренең күчермәләре;

2) күпфатирлы йорт турында мәгълүмат (күпфатирлы йортның ничә катлы булуы, гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак урыннарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, файдалануга тапшыру елы, соңгы капиталь ремонт елы);

3) урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фонды булдыруның сайлап алынган алымы турында хәбәрнамә;

4) капиталь ремонт фонды булдыру алымын сайлап алу турында урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәләренең күчермәләре;

5) капиталь ремонт фонды булдыру һәм капиталь ремонт ясауны оештыру турындагы шартнамәнең күчермәләре;

6) реквизитларны күрсәтеп, региональ оператор счетын, счетларын ачу турында белешмә;

7) урыннар милекчеләреннән капиталь ремонт өчен кертемнәрнең региональ оператор счетына, счетларына керүен раслый торган документлар;

8) региональ оператор счетында, счетларында калган акчаларның күләме турында мәгълүмат.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында каралган белешмәләр махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына махсус счет ачылган вакыттан биш эш көне дәвамында, шул исәптән электрон рәвештә дә, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы билгеләгән тәртиптә тапшырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 һәм 3 пунктларында һәм 2 өлешендә каралган белешмәләр региональ оператор, махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органына ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның беренче числосына кадәр, шул исәптән электрон рәвештә дә, Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

4. Дәүләт торак күзәтчелеге органы әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләр реестрын, махсус счетлар реестрын алып бара, җирле үзидарә органына һәм региональ операторга урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондларын булдыру алымын сайлап алмаган һәм (яисә) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында хәбәр итә.

5. Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан торак фондыннан милек рәвешләренә бәйсез рәвештә файдалануга һәм аны саклауга федераль законнар нигезендә билгеләнгән таләпләрне, шул исәптән капиталь ремонт фондларын булдыруга, региональ оператор булдыруга һәм аның эшчәнлегенә таләпләрне бозуларны кисәтүгә, ачыклауга һәм булдырмауга юнәлдерелгән эшчәнлеген федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

13 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәмен бирү тәртибе һәм шартлары**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме (алга таба – дәүләт ярдәме) чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган ассигнованиеләр чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт ярдәме Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә төзелгән торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш кооперативларына яисә башка

махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына, идарә итүче оешмаларга, региональ операторга Россия Федерациясе Торак кодексы, башка федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелә.

3. Капиталь ремонт буенча региональ программаларны гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт ярдәме урыннар милекчеләре тарафыннан кулланыла торган капиталь ремонт фонды булдыру алымына бәйсез рәвештә бирелә.

14 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай дәвамында шушы Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 25 июне
№ 52-ТРЗ